ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

16 октябрь 2020 ел № 22

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 15 пункты, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше, Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Советының 2012 елның 19 декабрендәге 200 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына (Нурлат муниципаль районы Советының 2013 елның 10 сентябрендәге 256 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 210 номерлы, 2020 елның 21 маендагы 281 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасы белән территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин